Кукмара муниципаль районы
Күкшел авыл җирлеге Советы

# КАРАР

2022 елның «01» августы № 17

Кукмара муниципаль районы Күкшел авыл җирлегенең Күкшел торак пунктында «Кукмара муниципаль районы Күкшел авыл җирлегенең Күкшел авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2021 елның 25 ноябрендәге 2 номерлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Күкшел авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә Күкшел авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. 2022 елның 10 августына 16 сәгать 00 минутка «Кукмара муниципаль районы Күкшел авыл җирлегенең Күкшел авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2021 елның 25 ноябрендәге 2 номерлы Күкшел авылы гражданнар җыены карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләргә.

- «Ленин ур., 48а адресы буенча универсаль спорт мәйданчыгы өчен спорт инвентаре сатып алу һәм урнаштыру; (шартнамә буенча түләү)» сүзләрен:
- «Ленин ур., 48а адресы буенча универсаль спорт мәйданчыгы өчен киртәләр сатып алу һәм урнаштыру; (шартнамә буенча түләү)» сүзләренә алмаштырырга.

Халык җыенын Күкшел авылының Театр урамындагы 41 нче йорт адресы буенча авыл мәдәният йортында үткәрергә
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
«Кукмара муниципаль районы Күкшел авыл җирлегенең Күкшел авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2021 елның 25 ноябрендәге 2 номерлы Күкшел авылы гражданнар җыены карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертү белән килешәсезме:

- «Ленин ур., 48а адресы буенча универсаль спорт мәйданчыгы өчен спорт инвентаре сатып алу һәм урнаштыру; (шартнамә буенча түләү)» сүзләрен:

- «Ленин ур., 48а адресы буенча универсаль спорт мәйданчыгы өчен спорт инвентаре, киртәләр сатып алу һәм урнаштыру; (шартнамә буенча түләү)» сүзләренә алмаштырырга.

.

«РИЗА» «КАРШЫ»

Әлеге карарны авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Җирлек башлыгы Р.Р. Хәмидуллин